КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 сентябрь г.Казань № 944

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибенең 5 пунктында «утырышында» сүзеннән соң «йә Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша читтән торып» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив

штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча әлеге карар белән расланган ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәдә:

4.4 һәм 4.5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Ведомствоара комиссия секретаре:

Ведомствоара комиссия әгъзаларының алдан фикерен формалаштыру максатларында, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Ведомствоара комиссия әгъзалары адресына бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турында тәкъдимнәр җибәрүне тәэмин итә, мондый тәкъдимнең Ведомствоара комиссия әгъзасына җибәрелгән көннән ике эш көненнән дә артмый торган карап тикшерү срогын билгели;

Ведомствоара комиссия әгъзалары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдимне карап тикшерү срогы тәмамланган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, Ведомствоара комиссия әгъзаларының алдан әйтелгән фикерен Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша бюджет акчасы заказчысына (аның белән баш эш итүчегә) җиткеренү тәэмин итә;

Ведомствоара комиссия утырышына материаллар әзерләүне тәэмин итә;

ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Ведомствоара комиссия әгъзаларына чираттагы утырыш турында хәбәр итә һәм аларга утырышта карап тикшереләчәк материалларны җибәрә;

бюджет акчасы заказчысына (аның белән баш эш итүчегә) Ведомствоара комиссия утырышында аның тәкъдимен карап тикшерү йомгаклары буенча бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү (килештермәү) турында бәяләмә җибәрүне тәэмин итә.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышы аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, бюджет акчасы заказчысының (аның белән баш эш итүченең) Ведомствоара комиссия секретаре адресына бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдиме Ведомствоара комиссия секретаре адресына кертелгән көннән җиде эш көненнән дә соңга калмыйча һәм Ведомствоара комиссия әгъзалары ягыннан Ведомствоара комиссия әгъзаларының алдан әйтелгән фикерендә күрсәтелгән кимчелекләр (мондыйлар булган, Ведомствоара комиссия секретаре тарафыннан Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша бюджет акчасы заказчысына (аның белән баш эш итүчегә) җибәрелгән очракта) бетерелгәндә үткәрелә.»;

4.7 һәм 4.8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Ведомствоара комиссия карары, Ведомствоара комиссиянең утырышта катнашмаган әгъзаларының язма фикерләрен исәпкә алып, Ведомствоара комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш биреп кабул ителә һәм бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү (килештермәү) турында бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә, аңа Ведомствоара комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан кул куела. Тавышлар тигез булганда, Ведомствоара комиссия җитәкчесе яки аның утырышта рәислек итүче урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора. Карар читтән торып тавыш бирү юлы (сораштыру юлы) белән Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә кабул ителергә мөмкин. Кабул ителгән карарга имза кую әлеге системада тәэмин ителә.

4.8. Ведомствоара комиссия тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештермәү турында карар кабул итү өчен «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге ФЗ-44 номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибенең кушымтасында күрсәтелгән мәгълүмат бирелмәү (тулысынча бирелмәү), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарының 1 пунктында күрсәтелгән факторлар булу расланмау нигез булып тора.»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча әлеге карар белән расланган ведомствоара комиссия составында:

Ведомствоара комиссия составыннан А.А.Кәримовны, А.А.Яфизовны чыгарырга;

Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Владимирович Коробченконы кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин